**КАРАР**

Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге
Үрнәк авылында халык җыены нәтиҗәләре турында

**“19” ноябрь 2022 ел** **№ 11**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1,56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2022 елның 19 ноябрендә түбәндәге мәсьәлә буенча үткәрелгән халык җыеннары нәтиҗәләре белән халык җыены беркетмәсе төзелде:

«Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Үрнәк авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын, балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Җирле әһәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү;

2) Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту?»

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

Халык җыены нәтиҗәләре беркетмәсе нигезендә сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 661 кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 338 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучылар тавышы түбәндәгечә бүленде: "Әйе" позициясе өчен халык җыенында катнашкан 338 кеше тавыш бирде; “Каршы" позициясе өчен җыенда катнашкан 0 кеше тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Үрнәк авылында халык җыенын булып узган дип танырга, халык җыены нәтиҗәләре дөрес.

2. «Сез 2023 елда яшәү урыны буенча Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге Үрнәк авылы территориясендә теркәлгән һәр балигъ булган кешегә, түләү күләме 150 сум тәшкил иткән, 1 нче төркем инвалидлардан, көндезге формада белем алучы студентлардан тыш, 300 сум күләмендә үзара салым кертү, шулай ук махсус хәрби операциядә катнашучыларны (контракт буенча хәрби хезмәткәрләрне, мобилизацияләнгән, үз ихтыяры белән махсус хәрби операциядә катнашкан затларны) һәм аларның гаилә әгъзаларын (бергә яшәүче ата-аналарын, хатынын,

балигъ булган балаларын) түләүдән азат итү һәм алынган акчаларны җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлдерү белән килешәсезме:

1) Җирле әһәмияттәге юлларның буйга профилен төзәтү;

2) Торак пунктларда кышкы чорда җирле әһәмияттәге юлларны кардан чистарту?

- мәсьәләсе буенча карар кабул ителгән дип таныйрга.

Аерым мәсьәләләр буенча экономия барлыкка килгән очракта, авыл җирлеге башкарма комитетына акчаны җыенда билгеләнгән башка мәсьәләләрне хәл итү өчен җибәрергә рөхсәт итәргә.

3. Әлеге карарны кабул ителгән көннән 7 көн эчендә, Үрнәк авыл җирлеге, Үрнәк авылы мәгълүмат стендында, Арча муниципаль районның (http://arsk.tatarstan.ru) рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында (http://pravo.tatarstan.ru) урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә.

4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Арча муниципаль районы Үрнәк авыл җирлеге башлыгына җибәрергә.

Халык җыенында рәислек итүче,
Арча муниципаль районы
Үрнәк авыл җирлеге башлыгы В.Р.Габделхаков